| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАГАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАГАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.12.2025ел. Багай ав. № 14

«Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Багай авыл җирлеге Башкарма комитетының 2024 елның 22 ноябрендәге 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 31 июлендәге 304-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Багай авыл җирлеге Башкарма комитетының 2024 елның 22 ноябрендәге 9 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2.5.1 пунктының 4 пунктчасында «мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси мәгълүматларын эшкәртү кирәк,» сүзләрен «мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси мәгълүматларын мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирү һәм аларны эшкәртү кирәк» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында һәм http://bagaev-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының
Багай авыл җирлеге Башкарма комитеты
Җитәкчесе Р.Ф.Кузнецова